ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

17.10.2023 г.Зеленодольск № АД-1305

О проведении IV Межрегиональных
чтений имени Равиля Сайфутдинова

Во исполнение плана работы Управления образования Исполнительного комитета Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан на 2023 - 2024 учебный год, в рамках межрегионального сотрудничества с регионами Российской Федерации, в целях развития творческого потенциала учащихся, выявления талантливых, одаренных детей и приобщения их к исследовательской, творческой деятельности

1. Провести 29 ноября 2023 года IV Межрегиональные чтения, посвященные творчеству поэта - земляка, педагога Равиля Сайфутдинова (далее – Чтения) на базе МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №16 с углубленным изучением отдельных предметов Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан».

2. Утвердить Положение межрегиональных чтений (приложение).

3. Директору МБОУ «СОШ №16 с УИОП ЗМР РТ» Сайфутдинову Р.Р. создать необходимые условия для проведения Чтений.

4. Руководителям общеобразовательных организаций направить заявки и работы обучающихся в соответствии с требованиями положения в срок до 20 ноября 2023 года, обеспечить участие обучающихся в Чтениях.

5. Контроль за исполнением настоящего распоряжения возложить на заместителя начальника Управления образования Исполнительного комитета Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан Э.Ф. Максимову.

Руководитель З.Ф. Хабибуллин

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00CD56A1864D5450B87F72C49E7125A3AA
Владелец: Хабибуллин Зульфат Флунович
Действителен с 07.08.2023 до 30.10.2024

Приложение
к распоряжению Исполнительного комитета
Зеленодольского муниципального района
_________________№ _________________

**ПОЛОЖЕНИЕ**
**о проведении IV Межрегиональных чтений имени Равиля Сайфутдинова, посвященных творчеству поэта - земляка, педагога Равиля Сайфутдинова**

**Укытучы, шагыйрь Равил Сәйфетдинов иҗатына багышланган IV Төбәкара Равил Сәйфетдинов укуларын үткәрү турында нигезләмә**

| **Оештыручылар:** | **Организаторы:** |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе<br><br>«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br><br>«Кызылбай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль казна гомуми белем бирү учреждениесе, Курган өлкәсе | Управление образования Исполнительного комитета Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан<br>Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «СОШ №16 с углубленным изучением отдельных предметов Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан»<br><br>Муниципальное казённое общеобразовательное учреждение «Кызылбаевская средняя общеобразовательная школа», Курганская область |
| **I. Гомуми нигезләмәләр (шартлар)**<br>1.1. Әлеге Нигезләмә Равил Сәйфетдинов исемендәге IV Төбәкара укуларының статусын, максатларын һәм бурычларын, оештыру һәм үткәрү тәртибен (алга таба – Бәйге), аны үткәрү форматын, шартларын һәм вакытын (срокларын), катнашучыларга һәм конкурс эшләренә карата таләпләрне билгели.<br>**II. Укуларның максаты һәм бурычлары**<br>2.1. Максаты – укучыларның иҗади потенциалын ачыклау, аларны шагыйрь, педагог Равил Сәйфетдиновның иҗади мирасына | **I. Общие положения**<br>1.1. Настоящее Положение определяет статус, цели и задачи, порядок организации и проведения IV Межрегиональных чтений имени Равиля Сайфутдинова (далее – Чтений), формат, условия и сроки его проведения, требования к участникам и конкурсным работам.<br><br>**II. Цели и задачи Чтений**<br>2.1. Целью Чтений является выявление творческого потенциала обучающихся, приобщение их к творческому наследию поэта, педагога Равиля Сайфутдинова |

| | |
|---|---|
| җәлеп итү.<br>2.2. Бурычлары:<br>- Равил Сәйфетдиновның иҗади мирасын өйрәнү өчен, мәйданчык булдыру;<br>- шагыйрь, педагог Равил Сәйфетдиновның тормыш юлын өйрәнү, иҗади мирасын пропагандалау һәм популярлаштыру;<br>- үсеп килүче буынны патриотизм һәм кече Ватанга мәхәббәт рухында тәрбияләү;<br>- талантлы, иҗади фикер йөртә торган балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү, аларны фәнни-тикшеренү һәм иҗади эшчәнлеккә тарту;<br>- укытучылар эшчәнлегенең алдынгы тәҗрибәсен тарату. | <br>2.2. Задачи:<br>- создание площадки для изучения творческого наследия Равиля Сайфутдинова;<br>- изучение жизненного пути, пропаганда и популяризация творческого наследия поэта, педагога Равиля Сайфутдинова;<br>- воспитание подрастающего поколения в духе патриотизма и любви к малой Родине;<br>- выявление и поддержка талантливых, творчески мыслящих детей и приобщение их к научно-исследовательской и творческой деятельности;<br>- распространение передового опыта педагогической деятельности учителей. |
| **III. Катнашучылар:**<br>3.1. Яшел Үзән муниципаль районы мәктәпләренең, «Кызылбай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль казна гомуми белем бирү учреждениесенең 1-11 нче сыйныф укучылары һәм укытучылар катнаша.<br>3.2. Катнашучыларның яшь төркемнәре:<br>- кече төркем – 1-4 нче сыйныфлар;<br>- урта төркем – 5-8 нче сыйныфлар;<br>- өлкән төркем – 9-11 нче сыйныфлар;<br>- педагоглар (укытучылар), мәктәп хезмәткәрләре.<br>Җиңүчеләр һәм призерлар һәр яшь категориясендә билгеләнәчәк. | **III. Участники:**<br>3.1. В Чтениях принимают участие обучающиеся 1-11 классов и педагоги образовательных организаций Зеленодольского муниципального района, МКОУ «Кызылбаевская средняя общеобразовательная школа»<br>3.2. Возрастные группы участников:<br>- младшая группа – 1-4 классы;<br>- средняя группа – 5-8 классы;<br>- старшая группа – 9-11 классы;<br>- педагоги, работники ОУ.<br><br>Победители и призеры будут определяться в каждой возрастной категории. |
| **IV. Укуларны үткәрү шартлары:**<br>4.1. Бәйгене үткәрү вакыты һәм урыны:<br>Гаризалар һәм эшләр 2023 нче елның 20 нче ноябренә кадәр кабул ителә;<br>Үткәрү вакыты – 2023 нче елның 29 нчы ноябре.<br>Үткәрү урыны – «ТР ЗМР 16 УГБМ» | **IV. Условия проведения Чтений:**<br>4.1. Время и место проведения:<br>Прием заявок и работ – до 20 ноября 2023 года;<br>Время проведения – 29 ноября 2023 года. |

| | |
|---|---|
| МБГБУ.<br>4.2. Татар, рус телләрендә башкарылган эшләр катнаша ала.<br><br>4.3. Эшләр түбәндәге **номинацияләр** буенча тәкъдим ителергә мөмкин:<br>**1. Равил Сәйфетдинов әсәрләрен уку бәйгесе**<br>1.1. Равил Сәйфетдинов әсәрләрен уку.<br>1.2. Укытучылар һәм остазлар елы уңаеннан Равил Сәйфетдиновның укытучыларга, мәктәп тормышына багышланган әсәрләрен сөйләү.<br>**2. «Каләм тибрәтү» бәйгесе**<br>Конкурста катнашучылар Равил Сәйфетдинов иҗатына багышланган үзләре иҗат иткән шигырьләрне сөйлиләр. Эшләр электрон вариантта (gismatullina.81@mail.ru) һәм бәйге үткәреләсе көнне басма вариантларда кабул ителә.<br>**3. «Равил Сәйфетдинов иҗаты – рәсемнәрдә» бәйгесе**<br>Катнашучылар Равил Сәйфетдиновның әсәрләре буенча ясалган рәсемнәрне тәкъдим итәләр. Конкурска А3, А4 кәгазендә төсле башкаруда төрле чаралар кулланып ясалган рәсемнәр кабул ителә. Рәсемнәрне Яшел Үзән муниципаль районы Мәгариф идарәсе бинасының 9 нчы бүлмәсенә тапшырырга.<br>**4. Равил Сәйфетдиновның тормышы һәм иҗаты буенча тикшеренү һәм проект эшләре**<br>Тикшеренү эше фәнни эшләргә куелган таләпләргә туры китереп башкарылырга тиеш. Эшне дөрес һәм төгәл башкару яшь авторның фәнни әзерлеген һәм гомуми культурасын күрсәтә, эшне укырга һәм бәяләргә ярдәм итә.<br>1) Текстны җыю таләпләре – А4; битнең кырыйлары: өстән һәм астан – 2 см, сул яктан – 3 см, уң яктан – 1,5 | Место проведения – МБОУ «СОШ №16 с УИОП ЗМР РТ».<br>4.2. К участию допускаются работы, выполненные на татарском, русском языках.<br>4.3. **Номинации**:<br>**1. Конкурс чтецов произведений Равиля Сайфутдинова**<br>1.1. Чтение произведений Равиля Сайфутдинова.<br>1.2. В рамках Года педагога и наставника чтение произведений Равиля Сайфутдинова, посвященных учителям и школьной жизни.<br><br>**2. Конкурс «Проба пера»**<br>Участники Конкурса представляют стихи собственного сочинения, посвященные творчеству Равиля Сайфутдинова. Работы принимаются в электронном варианте (gismatullina.81@mail.ru) и на бумажном носителе.<br>**3. Конкурс рисунков «Равиль Сайфутдинов глазами детей»**<br>Участники предоставляют рисунки, выполненные по произведениям Равиля Сайфутдинова. На Конкурс принимаются изображения рисунков, выполненные в цветном исполнении на бумаге А3, А4 с использованием средств для рисования. Рисунки предоставить в кабинет № 9 УО ИК ЗМР РТ<br>**4. Конкурс исследовательских и проектных работ по жизни и творчеству Равиля Сайфутдинова**<br>К исследовательской работе школьника, ее оформлению предъявляются те же требования, что и к любой научной работе. Необходимо придерживаться стандартов и правил, выработанных за многие годы в научной литературе. Правильное оформление работы говорит о научной |

| | |
|---|---|
| см; Times New Roman шрифты; 14 нче кегль; юл аралары интервалы 1,5.<br>2) Библиографик мәгълүматлар түбәндә күрсәтелгән үрнәк буенча тутырыла:<br>Фамилия И. А.и. Китап исеме. – Шәһәр исеме: Нәшрият, басылу елы. – Битләр саны.<br>3) Сылтамалар абзац яки җөмлә ахырында бирелә. Квадрат җәяләр эчендә, әдәбият исемлегендәге номерына карап, мәгълүмат чыганагының номеры һәм нокталы өтердән соң бит саны языла [3; 94 б.].<br>4) Эшнең беренче бите – титул бит (1 нче кушымтаны карагыз). Татар телендә язылган эшнең титул бите татар телендә булуы мәҗбүри.<br>5) Титул битеннән соң эшнең эчтәлеге бирелә. Анда барысы да стандарт схема буенча язылырга тиеш: эчтәлек, кереш сүз, ...нче бүлек, йомгак, әдәбият исемлеге, кушымта.<br>6) Битләр саны титул битеннән башлап санала (титул битенә сан куелмый) һәм кушымтага кадәр дәвам итә. Битләрнең номерлары астагы уң почмакта куелырга тиеш.<br>7) Кушымтада теоретик һәм гамәли эшчәнлекнең нәтиҗәләре: таблицалар, графиклар, диаграммалар, рәсемнәр, схемалар һ.б. рәвешендә урнаштырылырга мөмкин; битләр саны чикләнмәгән.<br>8) Эшнең «ЭЧТӘЛЕК», «КЕРЕШ СҮЗ», БҮЛЕК ИСЕМЕ, «ЙОМГАК», «ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ» кебек төп бүлекләренең исемнәре куштырнаксыз, калын баш хәрефләр белән уртада языла, параграф исемнәре (беренче хәреф баш хәрефтән языла) юл хәрефләре белән уртада языла. Бүлек исеменнән соң нокта куелмый. Бүлек исеме битнең башында урнаштырыла. | и общей культуре юного исследователя, делает работу удобной для чтения и оценки.<br>1) Рекомендуемое форматирование текста - А4, поля: сверху и снизу - 2 см, слева - 3 см, справа -1 ,5 см; шрифт Times New Roman, 14-й кегль, межстрочный интервал 1,5;<br>2) Оформление библиографических данных - по образцу:<br>Фамилия И. О. Название книги. - Город издания: Издательство, год издания. -Кол-во страниц.<br>3) Ссылки размещаются в конце предложения или абзаца по мере упоминания. В тексте в квадратных скобках указывается номер источника информации согласно списку использованной литературы и после точки с запятой номер страницы [3, с. 94].<br>4) Первая страница работы представляет собой титульный лист (Приложение 1).<br>5) Оглавление следует за титульным листом и выполняется по схеме: введение, глава …, заключение (выводы), список литературы, приложение.<br>6) Нумерация страниц начинается с титульного листа (при этом на нем самом номер не указывается) и заканчивается приложениями. Номера страниц должны располагаться в правом нижнем углу.<br>7) В приложении могут быть представлены результаты теоретической и практической деятельности в виде таблиц, графиков, диаграмм, рисунков, схем и др.; нет ограничения по количеству страниц.<br>8) Заголовки основных частей работы «СОДЕРЖАНИЕ», «ВВЕДЕНИЕ», НАЗВАНИЯ ГЛАВ, «СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ», «ЗАКЛЮЧЕНИЕ», |

| | |
|---|---|
| 9) Эшнең һәр структур өлешен яңа биттән башларга кирәк.<br>Эшләр рус, татар телләрендә башкарылырга мөмкин. Эшнең күләме һәм битләр саны чикләнмәгән.<br><br>**5. Методик эшкәртмәләр бәйгесе**<br>Педагогик хезмәткәрләр шагыйрь, педагог Равил Сәйфетдиновның тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнү буенча дәресләр, сыйныф сәгатьләре һәм сыйныфтан тыш чаралар тәкъдим итә. Материаллар электрон вариантта (gismatullina.81@mail.ru) кабул ителә.<br><br>4.5. Бәйгедә катнашу өчен, 2023 нче елның 20 нче ноябренә кадәр Оештыру комитетының электрон адресына гариза һәм иҗади эш җибәрергә кирәк: (gismatullina.81@mail.ru)<br>4.6. Барлык кызыксындырган сораулар буенча югары квалификацион категорияле туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы Гайсина Суфия Искәндәр кызына мөрәҗәгать итәргә.<br>тел. 89046637609, (gismatullina.81@mail.ru)<br>**V. Йомгак ясау**<br>Бәйгедә катнашучылар дипломнар һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнәчәк.<br>Бәйге турында мәгълүмат «ТР ЗМР 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» сайтында урнаштырыла.<br>https://edu.tatar.ru/z_dol/sch16/page4752 | «ПРИЛОЖЕНИЕ» пишутся без кавычек, прописными буквами жирным шрифтом с выравниванием по центру, а заголовки параграфов – строчными (кроме первой прописной) также с выравниванием по центру. Переносы в заголовках не допускаются. Точку в конце заголовка не ставят. Заголовок от текста отделяют одним пробелом. Нельзя печатать заголовок в конце страницы.<br>9) Каждую структурную часть работы следует начинать с нового листа.<br>Работы могут быть выполнены на русском, татарском языках. Объем и количество страниц работы не ограничены.<br>**5. Конкурс методических разработок**<br>Педагогические работники предоставляют разработки уроков, классных часов и внеклассных мероприятий по изучению жизни и творчества поэта, педагога Равиля Сайфутдинова. Работы принимаются в электронном варианте (gismatullina.81@mail.ru)<br>4.5. Для участия в Чтениях необходимо направить заявку участника и творческую работу в организационный комитет до 20 ноября 2023 года на электронный адрес: (gismatullina.81@mail.ru)<br>4.6. По всем интересующим вопросам обращаться к учителю родного (татарского) языка и литературы первой квалификационной категории Гисматуллиной Гузелии Наилевне.<br>тел. 89172338363,<br>(gismatullina.8 1@mail.ru)<br><br>**V. Подведение итогов Чтений**<br>Участники награждаются дипломами и Благодарственными письмами Управления образования ИК ЗМР РТ.<br>Информация о Чтениях размещается |

| | |
|---|---|
| 524.htm<br>**VI.** Равил Сәйфетдинов әсәрләре, II һәм III Укуларда тупланган иң яхшы эшләр мәктәпнең рәсми сайтына урнаштырылган. Равил Сәйфетдиновның укытучыларга һәм мәктәп тормышына багышланган әсәрләре IV Укулар бүлегендә бирелә.<br>https://edu.tatar.ru/z_dol/sch16/page4752524.htm | на сайте МБОУ «СОШ №16 с УИОП МР РТ»<br>https://edu.tatar.ru/z_dol/sch16/page4752524.htm<br>**VI.** Произведения Равиля Сайфутдинова, лучшие работы участников II и III Чтений размещены на официальном сайте МБОУ «СОШ №16 ЗМР РТ». В разделе IV Чтений размещены произведения Равиля Сайфутдинова посвященные учителям и школьной жизни.<br>https://edu.tatar.ru/z_dol/sch16/page4752524.htm |

**Образец титульного листа/ Титул битенең үрнәге**

Название учебного заведения (полностью)/ Уку йортының исеме
(шрифт Times New Roman, 14-й кегль)

Исследовательская работа/ Тикшеренү эше
Тема: «**Наименование работы**»/ Тема: **«Эшнең исеме»**
(шрифт Times New Roman, 16-й кегль)

Эшнең авторы:
Автор работы: (14-й кегль)
Фамилия, имя (полностью), класс,
учебное заведение
Фәнни җитәкче:
Руководитель:
ФИО (полностью), должность
(14-й кегль)

Населенный пункт/год (14-й кегль)
Торак пункт/ел

**Катнашучының гаризасы**

| | |
|---|---|
| Ф.И.О. участника / Катнашучының Ф. И. А.и. | |
| Тема работы / Эшнең темасы | |
| Почтовый адрес места жительства участника / Катнашучының өй адресы | |
| Телефон участника/ Катнашучының телефоны | |
| Адрес электронной почты участника / Катнашучының электрон почтасы | |
| Ф.И.О. научного руководителя (учителя) / Фәнни җитәкченең (укытучының) Ф. И. А.и. | |
| Телефон научного руководителя (учителя) / Фәнни җитәкченең (укытучының) телефоны | |
| Название места учебы участника и работы научного руководителя (общеобразовательного учреждения) / Катнашучының, фәнни җитәкченең (укытучының) уку һәм эш урыннары (уку йортының) | |
| Почтовый адрес общеобразовательного учреждения / Уку йортының почта адресы | |

## Тарихи белешмә

**«Мөгаллим дә, шагыйрь дә булган сәләтле шәхес»**
***Илдар Юзеев***

Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы 1938 нче елның 14 нче октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туган. Урта мәктәпне бетергәч, 1965-1961 нче елларда Казан дәүләт унивеситетында укыган. 1961-1963 нче елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән. 1963-2007 нче елларда берөзлексез Мулла Иле мәктәбендә хезмәт иткән: авыл мөгаллиме буларак, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, немец теле, гарәп теле, дин тарихы фәннәрен укыткан. 1968-1970 нче елларда – завуч, 1971-2000 нче елларда мәктәп директоры булган. Ул – Россиянең мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы белән бүләкләнгән. Республика матбугатында педагогик хезмәтләре, әдәби әсәрләре әледән-әле басылып тора. Равил хәзрәт Сәйфетдин 2005 нче елдан алып Мулла Иле мәчете имам-хатыйбы вазифаларын башкарды. 2017 нче елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде. 2018 нче елның 10 нче февралендә вафат.

**Равил Сәйфетдиновның басылып чыккан кайбер әсәрләре исемлеге**

Кышкы каникулда // Яшь сталинчы, 1952, 10 гыйнвар.
Этюд // Татарстан яшьләре, 1957, 20 июнь.
Унсигез яшь // Татарстан яшьләре, 1958, 18 март.
Казашка // Казахстанская правда, 1958, 5 ноябрь.
Бер көн // Татарстан яшьләре, 1960, 4 октябрь.
Мәрмәр ташны үбә таң җиле // Татарстан яшьләре, 1960, 10 ноябрь.
Ватаныма // Татарстан яшьләре, 1960, 5 декабрь.
Күңел онытмас // Совет Татарстаны, 1961.
Шигырьләр // Совет әдәбияты, 1961, 6 сан.
Ферма кызына // Ярыш, 1961, 2 июль.
Шигырьләр // Совет әдәбияты, 1961, № 8.
Шигырьләр // Совет әдәбияты, 1968, № 8.
Мулла Иле мәктәбе тарихыннан // Идел ягы, 1970, 2 июнь.
Мәктәп өчен туган зат // Идел ягы, 1977, 5 гыйнвар.
Vкласста сочинение яздыру һәм аңа анализ ясау // Совет мәктәбе, 1977, №2.
Киң колач белән // Идел ягы, 1979, 7 февраль.
Иҗат кешеләре авылда // Социалистик Татарстан, 1979, 10 август.
Чын кеше турында сөйлим // Идел ягы, 1980, 16 гыйнвар.
Безнеңүзешчән артистлар // Идел ягы, 1980, 12 апрель.
Удар хезмәткә рухландыралар // Идел ягы, 1981, 29 май.
Шигырьләр // Совет мәктәбе, 1981 № 7.
Эш шатлык китерә // Идел ягы, 1981, 7 ноябрь.
Ай, ул май заводы // Совет Татарстаны, 1982, 27 гыйнвар.

Әдәбият укытуда җирле материаллар // Совет мәктәбе, 1982, № 2.
Минем бик яхшы күршеләрем // Идел ягы, 1982, 4 август.
Аны хезмәт яшәртә // Идел ягы, 1982, 9 октябрь.
Булачак шатлык белән яши // Идел ягы, 1983, 11 ноябрь.
Озату кичәсе // Идел ягы, 1984, 20 октябрь.
Районда әдәбият атналыгы // Идел ягы, 1985, 29 март.
Авылдашлар Гөлсемне онытмыйлар // Идел ягы, 1985, 15 май.
Бурычлар үтәлерлек // Идел ягы, 1986, 18 февраль.
Содружество кафедры и школы // Совет мәктәбе, 1987, № 2.
Аяз Гыйләҗев белән очрашу // Идел ягы, 1987, 26 декабрь.
"Язгы аҗаган" романы буенча конференция-диспут // Совет мәктәбе, 1988, № 7.
Гаилә традициясе буенча // Идел ягы, 1989, 25 апрель.
Д.Лондонның "Яшәүгә мәхәббәт" хикәясе буенча дәрес-конференция // Мәгариф, 1990, № 1.
Авыл юбилее // Идел ягы, 1990.
Татар мәктәбе // Идел ягы, 1991, 23 февраль.
Тел белү – ярты бәхет // Шәһри Казан, 1991, № 207.
Шигырьләр // Ватаным Татарстан, 1991, 26 апрель.
Шигырьләр // Татарстан хәбәрләре, 1994, 11 февраль.
Гомерлек юксыну // Яшел Үзән, 1995, 7 май.
Безнең авыл мулласы // Ватаным Татарстан, 1996, 19 апрель.
Мулла Иле – изге җир // Мәгариф, 1996, №11.
Яшьлек яши безнең йөрәктә. Шигырьләр җыентыгы // Яшел Үзән, 1997.
Эшең – эзең // Мәгърифәт, 1997, 9 май.
Мулла Иле авылы булсын да // Яшел Үзән, 1997, 10 июнь.
Матурлык // Ватаным Татарстан, 1997, 17 октябрь.
Шигырьләр // Мәгариф, 1997, № 11.
Хәсән Туфан турында истәлекләрем // Яшел Үзән, 2000, 8 декабрь.
Что я думаю о суверенитете // Казанские ведомости, 2000.
Дәһшәтле елларда // Яшел Үзән, 2000, 1 февраль.
Кичке шәфәкъ. Шигырьләр җыентыгы // Казан, 2001.
Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов иҗаты турында // Ватаным Татарстан, 2001, 18 апрель.
Һәйкәлләре монда әтиләрнең // Ватаным Татарстан, 2001, 20 июль.
Һәвәскәр галим // Яшел Үзән, 2001, 20 ноябрь.
Кара кеше // Ватаным Татарсан, 2002, 20 декабрь.
Мулла Иле – изге җир // Сборник материалов научно-практической конференции "Историко-культурное наследие Зеленодольского района", г. Зеленодольск, 2003, стр.132-192
Шигырьләр // Ватаным Татарстан, 2004, 21 май.
Мине игелекле мөселман дип санавыгызны үтенәм (Лев Толстой турында) // Яшел Үзән, 2005, 3 ноябрь.
Чын кеше һәм чын язучы (А. Вергазов турында) // Яшел Үзән, 2007, № 23.
Азат күңелендә – шау чәчәкле бакча // Мәгърифәт, 2007, 5 май.
Динебез тарихы сәхифәләре // Яшел Үзән, 2007, 21 декабрь.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Шигырь һәм музыка хәраммы? // Мөселман календаре, Казан, 2010, 29 гыйнвар-4 февраль.
Мулла Иле моңнары. Шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр җыентыгы. // Казан, 2010.
Кадерен белик // Ватаным Татарстан, 2011, 21 май.
Тукай туган көндә // Яшел Үзән, 2011, 27 май.
Тарихларыбыз бергә үрелгән // Яшел Үзән, 2011, ноябрь.
Татар теле (5 нче сыйныф өчен дәреслек), Казан, 2012.
Теләктәшлек һәм туганлык көне // Яшел Үзән, 2012, 25 октябрь.
Шигырьләр // Мәгариф, 2012.
Киндер // Яшел Үзән, 2013, 3 май.
Минем мәхәлләм – минем мәчетем // Яшел Үзән, 2013, 3 май.
Нәсел шәҗәрәсе ниләр сөйли? // Яшел Үзән, 2013, 4 октябрь, № 75.
Бәхет үзәне: шигырьләр, поэма // Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014.
Тукай – Мулла Илендә // Ватаным Татарстан,15.08.2015, № 119.
Аксакал язмалары. Шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр җыентыгы // Казан, 2017.
Тукай һәм Тау ягы // Яшел Үзән, 2018, 25 апрель, №29.
Галиуллин Тәлгат Нәби улы, Сайланма әсәрләр, Казан, 2013, 489-510 нче битләрдәге “Шигырь Мәҗнүне” мәкаләсе

Лист согласования к документу № АД-1305 от 17.10.2023
Инициатор согласования: Лутфуллина Е.Б. Методист по профессиональному росту педагога информационно-методического отдела Управления образования Исполнительного комитета Зеленодольского муниципального района
Согласование инициировано: 16.10.2023 08:58

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Гайсина О.Б. | | Согласовано<br>17.10.2023 - 15:38 | - |
| 2 | Максимова Э.Ф. | | Согласовано<br>17.10.2023 - 15:48 | - |
| 3 | Хабибуллин З.Ф. | | Подписано<br>17.10.2023 - 16:21 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН